**РАСЛЫЙМ**
«Идел» журналының
баш мөхәррире
Р.Р. Сабиров
____________________
«28» 01 ________ 2019 ел

**РАСЛЫЙМ**
«Россия ислам институты» ректоры
Р.М. Мөхәмәтшин
____________________
«28» 01 ________ 2019 ел

# «Таян Аллага» әдәби конкурсының
# НИГЕЗЛӘМӘСЕ

## I. Конкурсның гомуми нигезләмәләре

**1.1**. "Таян Аллага" әдәби конкурсы Россия Федерациясендә яшәүче татар яшьләре арасында яшь талантларны барлау һәм берләштерү, аларның иҗади эшчәнлекләрен үстерү максатында уздырыла.

Конкурсның бурычлары:

- сәләтле яшьләргә иҗади үсеш өчен шартлар булдыру;
- татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен һәм ислам динен пропагандалау.

Оештыручылар:

"Идел" журналы, Россия ислам институты.

**1.2.** Вакыты һәм үткәрү тәртибе

Конкурс өч этапта үтә:

1 этап — әсәрләрне җыю (28 гыйнвар 2019 ел – 31 август 2019 ел)

2 этап — әсәрләрне жюри тарафыннан бәяләү (1 сентябрь – 30 сентябрь 2019 ел).

3 этап — җиңүчеләрне билгеләү (октябрь 2019 ел).

## II. Конкурста катнашу шартлары

**2.1.** Конкурста Россия Федерациясендә яшәүче 10 яшьтән 35 яшькә кадәрле һәрбер теләгән кеше катнаша ала.

**2.2.** Конкурс иҗат эше белән профессиональ рәвештә шөгыльләнмәүче яшьләр өчен үткәрелә, профессиональ язучыларның, шагыйрьләрнең, журналистларның әсәрләре һәм язмалары кабул ителми.

**2.3.** Конкурс дүрт номинациядә үтә:

- шигърият,
- чәчмә әсәр,
- драматургия,
- публицистик язма.

**2.4.** Конкурска тәкъдим ителгән әсәрләр һәм мәкаләләр **әдәби татар телендә** язылырга тиеш.

**2.5.** Аз күләмле әсәрләр (шигырьләр, кыска хикәяләр һ.б.) һәм публицистик язмалар өчтән дә ким булмаска тиеш. Аларны түбәндәге таләпләргә туры китереп эшләргә кирәк: Times New Roman шрифтында, 14 нче кегль, бер ярым интервалда, сул яктан – 30 мм, уң яктан – 10 мм, өстән – 25 мм, астан – 20 мм.

**2.6.** Конкурска язмалар электрон вариантта кабул ителә. Конкурс материалларын җибәрү өчен электрон адрес: tatarkonkurs@mail.ru

**2.7.** Әсәрләр белән бергә конкурста катнашучы үзе турында кыскача мәгълүмат, адресын һәм телефон номерын җибәрергә тиеш. Конкурска җибәрелгән материалларны алып теркәгәннән соң, оештыру комитеты авторларның электрон почтасына раслау җибәрә. Конкурс белән бәйле барлык мәгълүматлар да сайтка урнаштырылачак http://www.kazanriu.ru.

**III. Конкурска йомгак ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү**

3.1. Конкурста катнашучыларның әсәрләрен анализлау һәм бәяләү өчен оештыру комитеты тарафыннан махсус комиссия (жюри) билгеләнә.

3.2. Комиссия, конкурска килгән язмаларны тикшереп, һәр номинациядә беренче, икенче, өченче урыннарны һәм гран-прига лаек әсәрне билгели. Моннан тыш, махсус бүләкләр булуы да мөмкин.

Жюри гран-при һәм призлы урыннарны бирмәү хокукына да ия.

Конкурс нәтиҗәләре буенча лаеклы дип табылган әсәрләр «Идел» журналы битләрендә урын алачак.

Оештыру комитеты адресы: Казан ш., Газовая урамы, 19 нчы йорт. Татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы. E-mail: tatarkonkurs@mail.ru

Белешмәләр өчен телефон: 8(843)2776826.